ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.04.2019 ел Баулы шәһәре №110

Планлаштырылган тезелеш турында белдерүдә күрсәтелгән индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объекты параметрлары җир участогында индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объекты урнаштыруның рөхсәт ителгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм аларны урнаштыру рехсәт ителү (ителмәү) турында белдерү җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән 210-ФЗ номерлы Федераль закон (2018 елның 29 июлендәге редакциядә) нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендә кабул ителгән 880нче номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» карарына (2018 елның 24 июлендәге редакциядә) таянып, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Кушымтадагы Планлаштырылган төзелеш турында белдерүдә күрсәтелгән индивидуаль торак тезелеше яисә бакча йорты объекты параметрлары җир участогында индивидуаль торак төзелеше яисә бакча йорты объекты урнаштыруның рехсәт ителгән параметрларга туры килүе (туры килмәве) һәм аларны урнаштыру рөхсәт ителү (ителмәү) турында белдерү җибәрү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Әлеге карарны http://www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм

http://www.bavly.tatarstan.ru. Адресы буенча Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров